РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬКЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛКИ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422870, ТР Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, Сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Базарлы Матак авылы **КАРАР**

2021 елның 20 марты 85№

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 5 февралендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы муниципаль белем бирү учреждениеләрен территорияләргә беркетү турында» 22 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 15 маендагы «Мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында» 236 номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 2 сентябрендәге «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында» 458 номерлы боерыгы нигезендә, белем бирү оешмалары арасында укучылар контингентын тигез бүлү һәм аларның оптималь тулылыгын тәэмин итү максатларында Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.1. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 5 февралендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы муниципаль белем бирү учреждениеләрен территорияләргә беркетү турында» 22 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.2. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ җитәкчесенә 2 айдан 18 яшькә кадәр булган балаларны: 2 айдан алты яшь 6 айга кадәр мәктәпкәчә белем алу, алты яшь алты айдан унсигез яшькә кадәр башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларында социаль-педагогик исәпкә алуны һәм беркетелгән территорияләр нигезендә укучыларны белем бирү оешмаларына кабул итүне тәэмин итү гарантияләрен үтәүгә мониторинг ясарга;»

1.3.Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми https://alkeevskiy.tatarstan.ru сайтында бастырып чыгарырга һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

1.4. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче: И. В. Юсупов